# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
# БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

“17” ноябрь 2020 ел Биклән авылы №7

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Кзыл-Юл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Биклән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 ст. нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Кзыл-Юл авылында 2021 елның 27 ноябрендә 13.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: “Биклән авыл җирлегенең Кзыл-Юл авылы территориясендә 2022 елда балигъ булган, Биклән авыл җирлегенең Кзыл-Юл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:
- Кзыл-Юл авылы эчендәге юлларны төзекләндерү

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Кзыл-Юл авылы, Үзәк урамы, 11нче йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Биклән авыл җирлеге Башлыгы М.Ш.Сәхбеев